ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

« 03 » март **2022 ел** **№** 148

**Арча муниципаль районында яңа короновирус йогышлы авыруы таралуны чикләү чаралары кертелүгә бәйле рәвештә шәһәр һәм (яисә) шәһәр яны маршрутларында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы юридик затларның һәм (яисә) шәхси эшкуарларның алынмаган керемнәрен каплау максатыннан Арча муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында**

Арча муниципаль районы территориясендә халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итүгә юнәлтелгән чикләү чараларын һәм башка чаралар комплексын гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус инфекциясе таралуны булдырмау чаралары турында» 2014 елның 19 мартындагы 208 номерлы карары нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 10 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Арча муниципаль районында яңа короновирус йогышлы авыруы таралуны чикләү чаралары кертелүгә бәйле рәвештә шәһәр һәм (яисә) шәһәр яны маршрутларында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы юридик затларның һәм (яисә) шәхси эшкуарларның алынмаган керемнәрен каплау максатыннан Арча муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен (1 нче кушымта) расларга.
2. Субсидия алу хокукына дәгъва кылучы юридик затларны, шәхси эшкуарларны сайлап алуны гамәлгә ашыручы комиссия составын әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка иҗиткерергә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.Ә.Галимуллин

1 нче кушымта

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
03.03.2022 ел, №148
карары белән расланды

Арча муниципаль районында яңа короновирус йогышлы авыруы таралуны чикләү чаралары кертелүгә бәйле рәвештә шәһәр һәм (яисә) шәһәр яны маршрутларында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы юридик затларның һәм (яисә) шәхси эшкуарларның алынмаган керемнәрен каплау максатыннан Арча муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип 2022 елда Арча муниципаль районында яңа короновирус йогышлы авыруы таралуны чикләү чаралары кертелүгә бәйле рәвештә шәһәр һәм (яисә) шәһәр яны маршрутларында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы юридик затларның һәм (яисә) шәхси эшкуарларның алынмаган керемнәрен каплау максатыннан Арча муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен, механизмын, максатларын һәм шартларын билгели.

1.2. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчаларының баш бүлүчесе -Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет).

1.3. Субсидияләр Арча район Советының тиешле финанс елына һәм план чорына бюджет турындагы карары белән каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм вәкаләтле органга - Арча муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге Тәртипнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максатларга каралган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

1.4. Субсидия бирү өчен юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне сайлап алу критерийлары булып коры җир пассажир транспорты эшчәнлеге: шәһәр эчендәге һәм шәһәр яны пассажирларын йөртү тора.

## II. Субсидия бирү шартлары һәм тәртибе

2.1. Субсидия бирү шартлары:

- әлеге Тәртип нигезендә субсидия алуга гариза һәм документлар бирү;
- әлеге Тәртипнең 2.3.1 пунктында күрсәтелгән субсидия алуга гариза һәм документларда тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге;
- Арча муниципаль районы Башкарма комитеты белән субсидия бирү турында килешү төзү;
- Арча муниципаль районы Башкарма комитетының «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә автомобиль транспортында йөрү өчен түләүнең автоматлаштырылган системасын гамәлгә кертү һәм аңа хезмәт күрсәтү буенча автоматлаштырылган система операторы (алга таба - АСОП операторы) белән үзара эшчәнлеген раслый торган документ булу.

2.2. Субсидиядән файдаланунның нәтиҗәлелеге күрсәткече (алга таба - нәтиҗәлелек күрсәткече) Арча муниципаль районында автомобиль транспортында пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда транспорт хезмәте күрсәтүнең ышанычлылыгы 2021 елда "Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары расписаниесен үтәү коэффициенты" күрсәткече ярдәмендә бәяләнә, ул > 0,7 булырга тиеш.

Арча муниципаль районында 2021 елда автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары расписаниесен үтәү коэффициенты түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$K_{\text{распj}} = \frac{Q_{\text{фактрейсj}}}{Q_{\text{рейсраспj}}} \geq 0{,}7,$$

биредә:
j - Арча муниципаль берәмлегендә транспорт төре: автобус;

Qфактрейс - Арча муниципаль районында 2021 елда пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны башкарганда башкарылган факттагы рейслар саны;

Qрейсраспj - i-нчы муниципаль берәмлектә 2021 елда расписаниедә билгеләнгән транспорт төре белән пассажирлар һәм багаж ташуны гамәлгә ашырган рейслар саны.

2.3. Субсидия бирү тәртибе:

2.3.1. Субсидия алу өчен гариза һәм документлар тапшырырга вәкаләтле затлар (алга таба - мөрәҗәгать итүчеләр) Арча муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм финанс бүлегенә түбәндәге документларны тапшыра:

1) субсидия бирү турында гариза;

2) мөрәҗәгать итүче тарафыннан аның җитәкчесенең вәкаләтләрен раслый торган документның таныкланган күчермәсе яисә ул вәкаләт биргән затка карата таныкланган ышанычнамә;

3) субсидия бирү максатларында автоматлаштырылган, шулай ук автоматлаштыру чараларыннан файдаланмыйча персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык, аерым алганда, "Персональ мәгълүматлар турында" 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктында каралган гамәлләр кылу, шәхси мәгълүматлар белән мондый чараларны кулланып башкарыла торган гамәлләрнең (операцияләрнең) тапшыру, блоклау, бетерү, юк итү;

4) субсидия биргән бюджет акчаларын баш бүлүче һәм муниципаль финанс контроле органы тарафыннан субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибенең үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалык;

5) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының әлеге карары белән расланган типлаштырылган форма нигезендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан имзаланган һәм мөрәҗәгать итүченең мөһере белән таныкланган субсидия бирү турында килешү (2 нче кушымта);

6) түбәндәгеләрне раслый торган документлар:

- Арча муниципаль районында юлда йөрү өчен түләү төрләре буенча 2021 елның сентябрь - октябрь айларында шәһәр яны муниципаль маршрутларында һәм шәһәр яны элемтәсендәге муниципаль маршрутларда автомобиль транспортында пассажирлар йөртүчеләрнең уртача тәүлеклеклек кереме (ташламалы транспорт кушымтасы булган электрон карталар, транспорт кушымтасы булган электрон карталар, банк карталары, кулдагы исәп-хисап);

22.11.2021 - 31.12.2021 вакыт аралыгында (алга таба-хисап чорында) шәһәр яны муниципаль берәмлегендә муниципаль маршрутларда һәм шәһәр яны элемтәсендәге муниципаль маршрутларда автомобиль транспортында пассажирлар йөртүчеләрнең кереме күләме (ташламалы транспорт кушымтасы булган электрон карталар, транспорт кушымтасы булган электрон карталар, банк карталары, кулдагы исәп-хисап);

2.3.2. Субсидия алучылар килешү төзү планлаштырылган айдан алдагы айның беренче числосына түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

субсидия алучыларның салымнар, җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, түләнергә тиешле процентлар (мондый таләп хокукый акт белән каралган очракта) түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаска тиеш;

субсидия алучыларның хокукый акт нигезендә субсидияләр бирү планлаштырыла торган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетына кире кайтару буенча кичектерелгән бурычы, аның бюджетыннан хокукый акт нигезендә (физик затларга субсидия алучылар тарафыннан товарлар китерүгә (эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә) бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү яки каплау максатларында муниципаль учреждениеләргә бирелә торган субсидияләрдән тыш) субсидияләр бирү планлаштырыла торган гавами-хокукый берәмлек алдында акчалата йөкләмәләр буенча кичектерелгән (җайга салынмаган) бурыч (шул исәптән бүтән хокукый актлар нигезендә) һәм башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләр, бюджет инвестицияләре булмаска тиеш;

субсидия алучылар үзгәртеп кору, бетерү процессында булмаска, аларга карата банкротлык процедурасы кертелмәскә, субсидия алучыларның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаска, шәхси эшкуарлар шәхси эшкуар сыйфатында эшчәнлеге туктатылмаска тиеш.

Арча муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм финанслар бүлеге:

- субсидия бирү турында гаризаны кергән көнне терки.

Субсидия алу хокукына дәгъва кылучы юридик затларны, шәхси эшкуарларны сайлап алуны гамәлгә ашыручы комиссия:

- 2 эш көненнән дә артык булмаган вакытта әлеге Тәртипнең 2.3.1 пунктында күрсәтелгән документларны карый һәм алынмаган керемнәрне каплауга субсидия бирү яисә субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә;

- Субсидия бирү турында тапшырылган гаризаны һәм аңа кушып тапшырылган документларны мөрәҗәгать итүчегә эшләп бетерү өчен кире бирү яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, гаризаны

һәм документларны теркәгән көннән алып 2 эш көненнән дә артык булмаган вакытта мөрәҗәгать итүчегә бу хакта теләсә нинди ысул белән хәбәр итә.

Субсидия бирү турында килешү төзүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

- әлеге Тәртипнең 2.3.1 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

- әлеге Тәртипнең 2.3.1 пунктында каралган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы.

2.3.4. Субсидия Арча муниципаль районы Башкарма комитетының исәп-хисап счетыннан әлеге Тәртип нигезендә субсидия бирү турында килешү имзаланганнан соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать итүченең исәп-хисап счетына кертелә.

2.3.5. Субсидия бирү турындагы килешүдә түбәндәгеләр карала:

- субсидиянең максатчан билгеләнеше;
- бирелә торган субсидия күләме;
- нәтиҗәлелек күрсәткече;
- субсидияләрне күчерү тәртибе һәм сроклары;
- нәтиҗәлелек күрсәткеченең ирешелгән күрсәткече турында хисап бирү сроклары һәм формалары;
- нәтиҗәлелек күрсәткеченең билгеләнгән күрсәткеченә җитмәве нәтиҗәләре;
- килешүдә каралган субсидияләр бирү максатының, шартларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибе;
- килешүнең шартларын бозган өчен якларның җаваплылыгы.

### III. Яңа коронавирус инфекциясе таралуны булдырмау максатыннан чикләү чаралары кертелүгә бәйле рәвештә автотранспорт предприятиеләренең алынмаган керемнәрен каплауга субсидия күләмен исәпләү

3.1. Субсидия күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары һәм пассажирлар транспортында йөрү өчен түләүнең автоматлаштырылган системасы операторы ("Транспорт картасы" АҖ) тарафыннан тапшырыла торган документлар нигезендә исәпләнә һәм түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$N = SUM ((Ср_{(тәүлеклек\ керем)} \times К_{көн}) - Факт_{(керем)},$$

биредә:

Ср (тәүлеклек керем) - АСОП операторы мәгълүматлары буенча йөк ташучыларның 2021 елның сентябрь-октябрендә шәһәр муниципаль маршрутларда һәм шәһәр яны юлларында автомобиль транспортында уртача тәүлеклек кереме;

Фактта (керем) - АСОП операторы мәгълүматлары буенча пассажир ташучыларның шәһәр һәм автомобиль транспортында шәһәр яны маршрутларында хисап чорындагы кереме;

К(көн)- хисап чорында көннәр саны.

## IV. Субсидияне кире кайтару тәртибе

4.1. Арча муниципаль районы Башкарма комитеты, муниципаль финанс контроле органы субсидия бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшерә.

4.2. Арча муниципаль районы Башкарма комитеты һәм муниципаль финанс контроле вәкаләтле органы үткәргән тикшерүләр фактлары буенча субсидияләр биргәндә билгеләнгән шартларны, максатларны һәм тәртибен бозу ачыкланган очракта, субсидия алучы вәкаләтле органның язма таләбе буенча субсидияләрне Арча муниципаль районы бюджетына кире кайтару турында таләп алынган көннән алып 10 эш көненнән дә соңга калмыйча кире кайтарырга тиеш. Субсидия билгеләнгән срокта кире кайтарылмаган очракта, ул гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә муниципаль берәмлек бюджеты керемәнә алына.

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
"03" 03.2022ел, №148
карарына 2 нче кушымта

Субсидия алу хокукына дәгъва кылучы юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне сайлап алуны гамәлгә ашыручы комиссия составы

| | |
|---|---|
| Шаһиәхмәтов Р.Д. | Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары |
| Гәрәев М. Р. | Арча муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенең шәһәр төзелеше һәм архитектура секторы мөдире |
| Галимуллина Г.Х. | Арча муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм финанс бүлеге башлыгы |
| Галиуллина Р.Р. | Арча муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге башлыгы |
| Собирова Г.Х. | Арча муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм финанс бүлеге баш белгече |

Арча муниципаль районында яңа короновирус йогышлы авыруы таралуны чикләү чаралары кертелүгә бәйле рәвештә шәһәр һәм (яисә) шәһәр яны маршрутларында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы юридик затларның һәм (яисә) шәхси эшкуарларның алынмаган керемнәрен каплау максатыннан Арча муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә 1 нче кушымта

**Субсидия бирү турында килешү №__**

«_____» ___________20 __ ел

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты, ________________________исеменнән ______________________________________ нигезендә эш итүче, алга таба - «Башкарма комитет» дип аталучы бер яктан һәм ____________________ нигезендә эш итүче, алга таба Субсидия алучы дипататлучы __________________________ икенче яктан, бергә Яклар дип аталачак, «Арча муниципаль районында яңа короновирус йогышлы авыруы таралуны чикләү чаралары кертелүгә бәйле рәвештә шәһәр һәм (яисә) шәһәр яны маршрутларында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы юридик затларның һәм (яисә) шәхси эшкуарларның алынмаган керемнәрен каплау максатыннан Арча муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» Арча муниципаль районы Башкарма комитетының _____________ ел, №__карары нигезендә түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр.

## 1. Килешү предметы

1.1. Килешү предметы булып шәһәр һәм (яисә) шәһәр яны юлларында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы Алучыга субсидияләр бирү тора, ул Россия Федерациясе бюджетлары чыгымнары классификациясе кодлары буенча Башкарма комитетка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә Арча муниципаль районы бюджетыннан алынган керемнәрне каплау максатларында, Арча муниципаль районы бюджетыннан алынган керемнәрне кире кайтару максатыннан, Арча муниципаль районында яңа коронавирус инфекциясе таралуны булдырмау максатыннан чикләү чаралары кертелүгә бәйле рәвештә, Россия Федерациясе бюджетлары чыгымнары классификациясе кодлары буенча башкарма комитетка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларына туры китереп, Арча муниципаль районы бюджетының баш бүлүче коды 828, 04 бүлек, 08 бүлек, максатчан статья 9900003170 811, чыгымнарның төре буенча субсидия бирү тора.

1.2. Әлеге Килешү нигезендә Субсидия алучыга Арча муниципаль районы бюджетыннан бирелә торган субсидиянең гомуми күләме ___________________________________ сум 00 тиен тәшкил итә.

## 2. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1. Башкарма комитет бурычлы:

2.1.1. Арча муниципаль районы бюджетыннан яңа короновирус йогышлы авыруы таралуны чикләү чаралары кертелүгә бәйле рәвештә шәһәр һәм (яисә) шәһәр яны маршрутларында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы юридик затларның һәм (яисә) шәхси эшкуарларның алынмаган керемнәрен каплау максатыннан 20__ финанс елына Башкарма комитетка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә Субсидия алучыга субсидия бирүне тәэмин итәргә;

2.1.2. Субсидия алучы тарафыннан субсидияләр бирү шартларын һәм әлеге Килешүдә каралган башка йөкләмәләрне үтәүне тикшереп торырга;

2.1.3. Субсидия алучы тарафыннан тапшырылган хисаплылык күрсәткечләре нигезендә әлеге Килешүнең 2.2.3 пункты нигезендә билгеләнгән субсидиядән файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткеченең күрсәткече күрсәткеченә ирешү йөкләмәләрен исәпкә алып, субсидиядән файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткечен бәяләүне гамәлгә ашырырга;

2.1.4. Субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү елның 31 декабренә торышы буенча әлеге килешүнең 2.2.3 пунктында каралган йөкләмәләрне бозуга юл куелган очракта һәм елда нәтиҗәләргә ирешү турында хисаплылыкны тапшыруның беренче датасына кадәр, субсидия бирү Тәртибе нигезендә билгеләнгән субсидия бирү елыннан алдагы елга кадәр бирелгән вакытта күрсәтелгән хокук бозулар бетерелмәгән, субсидия бирү тәртибе нигезендә Арча муниципаль районы бюджетына кайтарылырга тиешле акчалар күләмен исәпләп чыгарырга һәм күрсәтелгән күләмдә Арча муниципаль районы бюджетына субсидияләрне кире кайтару турындагы таләпне Субсидия алучыга җибәрергә;

2.1.5. Субсидия бирү туктатылган очракта, Субсидия алучыга мондый туктатылуның сәбәпләре турында хәбәр итәргә;

2.1.6. Россия Федерациясенең бюджет законнарында, субсидия бирү тәртибендә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән башка йөкләмәләрне үтәргә.

2.2. Субсидия алучының бурычлары:

2.2.1. субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү йөкләмәләрен бозган өчен Арча муниципаль районы бюджетына акчаларны кире кайтару буенча Башкарма комитет таләпләрен үтәүне тәэмин итәргә;

2.2.2. Субсидияне файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткеченә ирешүне тәэмин итәргә.

Субсидиядән файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткече (алга таба - нәтиҗәлелек күрсәткече) Алучы тарафыннан пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда транспорт хезмәте күрсәтүнең ышанычлылыгы «Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут расписаниесен үтәү коэффициенты» күрсәткече ярдәмендә бәяләнә, ул $\geq 0,7$. Нәтиҗәлелек күрсәткечен исәпләү субсидия бирү тәртибенең 2.2 пунктында күрсәтелгән формула буенча башкарыла.

2.2.3. әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып торучы кушымта нигезендә субсидиядән файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткече турында

Башкарма комитетта хисап бирүне тәэмин итәргә (хисап чорыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр хисап);

2.2.4. гарызнамә алган очракта, Субсидия алучының килешүдә каралган субсидия бирү шартларын һәм башка йөкләмәләрне үтәвен тикшереп тору өчен кирәкле документларны һәм материалларны, шул исәптән бухгалтерлык исәбе күрсәткечләрен һәм Субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү шартларын үтәүгә бәйле беренчел документларны тапшыруны тәэмин итәргә;

2.2.5. хисап чорыннан соң килүче финанс елның 1 гыйнварына файдаланылмаган, субсидияләрнең калган өлешен Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән срокларда Арча муниципаль районы бюджетына кайтарырга;

2.2.6. Россия Федерациясенең бюджет законнарында, субсидия бирү тәртибендә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән башка йөкләмәләрне үтәргә.

2.3. Башкарма комитет хокуклы:

2.3.1. Алучы тарафыннан әлеге килешү буенча йөкләмәләрне үтәүне тикшерүне башкарырга, шулай ук Субсидия алучыдан әлеге тикшерүне гамәлгә ашыру өчен кирәкле һәм җитәрлек мәгълүмат соратып алырга;

2.3.2. Россия Федерациясенең бюджет законнарында, субсидия бирү тәртибендә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

2.4. Субсидия алучы түбәндәгеләргә хокуклы:

2.4.1. Әлеге Килешүне үтәүгә бәйле рәвештә, башкарма комитетка аңлатмалар сорап мөрәҗәгать итәргә;

2.4.2. Россия Федерациясенең бюджет законнарында, субсидия бирү тәртибендә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

## 3. Субсидияләрне күчерү шартлары һәм сроклары

3.1. Субсидия әлеге Килешүнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максатларга субсидияләр бирү турында килешү төзелгән көннән алып 10 (ун) эш көненнән дә соңга калмыйча күчерелә.

3.2. Субсидия алучы тарафыннан субсидияне чит ил валютасы акчалары исәбеннән алу тыела, моңа югары технологияле импорт җиһазларын, чималны һәм комплектлаучы әйберләрне сатып алганда (китергәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган, шулай ук әлеге акчаларны күрсәтелгән юридик затларга субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларда, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән башка операцияләр бирү максатларына ирешү белән бәйле операцияләр керми.

3.3. Әлеге килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәү фактлары ачыкланган очракта, Башкарма комитет ачыкланган бозуларны бетергәнче Субсидия алучыга тиешле субсидияләрне күчермәскә хокуклы.

3.4. Субсидияләр субсидия алучының субсидияне бирү турындагы гаризасында күрсәтелгән Россия Федерациясендә урнашкан кредит

оешмасындагы исәп-хисап счетына күчерелә.

## 4. Субсидияләрне кире кайтару тәртибе

4.1. Субсидия алучы субсидия биргәндә билгеләнгән шартларны бозган очракта, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты күрсәтелгән хокук бозулар ачыкланган көннән алып 10 көн эчендә субсидия алучыга субсидияне кире кайтару турында хәбәрнамә җибәрә.

4.2. Әлеге Килешүнең 4.1 пунктында күрсәтелгән хәлләр ачыкланганда, субсидия алучылар субсидияне мөстәкыйль рәвештә яисә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты таләбе буенча кире кайтаралар.

4.3. Акчаларны кире кайтару Субсидия алучыга субсидияне кире кайтару турындагы таләпне, агымдагы елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча, җиткергән вакыттан алып җиде эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

4.4. Субсидияне кире кайтару хәбәрнамәдә күрсәтелгән Россия Федерациясе бюджетлары керемнәре классификациясенең реквизитлары һәм коды буенча башкарыла.

4.5. Субсидия алучы, тикшерелгән документлар нәтиҗәләре буенча билгеләнгән, шулай ук башка контроль чаралар үткәрү нәтиҗәсендә фактта барлыкка килгән керемнәрдән нигезсез рәвештә күрсәтелүче керемнәр күләмендә түләнгән керемнәр рәвешендә алынган бюджет акчаларын кире кайтарырга тиеш.

Ачыкланган бозулар комиссия тарафыннан акт белән рәсмиләштерелә һәм имзалана һәм Субсидия алучыга бирелә.

4.6. Әлеге Килешүнең 4.5 п. күрсәтелгән актны алган көннән алып 30 календарь көн эчендә Субсидия алучы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының шәхси счетына агымдагы финанс елында алынган акчаларны кире кайтарырга тиеш.

4.7. Әлеге Килешүненең 4.3, 4.6. пунктларын үтәмәгән очракта, сумма недоимка булып санала һәм аңа вакыты узган һәр көн өчен 0,1% күләмендә пеня өстәлә.

4.8. Субсидия биргәндә билгеләнгән шартларны бозып файдаланылган субсидияне, шулай ук тикшерү нәтиҗәләре буенча ачыкланган төшеп калган керемнәрнең нигезсез суммаларын бозып кире кайтармаган яисә ирекле кире кайтармаган очракта, түләтү Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә башкарыла.

## 5. Субсидиянең калган өлешләрен кире кайтару тәртибе

5.1. Субсидия алучы агымдагы финанс елында субсидиянең калган өлешен кире кайтара, субсидия алучының акчалата йөкләмәләрен түләү өчен кирәкле сумма чикләрендә бирелгән субсидияләрдән тыш.

5.2. Субсидиянең калган өлешен кире кайтару Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының шәхси счетына Субсидия алучы игътибарына субсидияне кире кайтару турындагы таләпне җиткергән

көннән алып агымдагы финанс елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча, тиешле акчаларны күчерү юлы белән җиде банк көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

5.3. Агымдагы елның декабрь аенда бирелгән субсидия тиешле субсидиядән артып киткән очракта, артык җибәрелгән сумма Арча муниципаль районы бюджетына хисап елыннан соң килүче елның 25 гыйнварына кадәр кайтарылырга тиеш.

**6. Якларның җаваплылыгы**

6.1. Әлеге Килешү буенча үз йөкләмәләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта, Яклар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

6.2. 2023 елның 1 гыйнварына файдаланылмаган субсидияләр 2023 елның беренче 15 эш көне эчендә Арча муниципаль районы бюджеты кеременә кайтарылырга тиеш.

**7. Йомгаклау нигезләмәләре**

7.1. Әлеге Килешүне үтәүгә бәйле рәвештә, Яклар арасында барлыкка килә торган бәхәсләр алар тарафыннан, мөмкин булганча, беркетмәләрне яисә башка документларны рәсмиләштерү белән сөйләшүләр үткәрү юлы белән хәл ителә. Килешүгә ирешмәгәндә, Яклар арасындагы бәхәсләр суд тәртибендә хәл ителә.

7.2. Әлеге Килешү Якларның һәркайсы исеменнән эш итәргә хокукы булган затлар аңа имза салган датадан үз көченә керә, әмма әлеге Килешүне предметы буенча бюджет йөкләмәләре башкарма лимитларын җиткергәннән дә иртәрәк түгел, һәм Якларның әлеге Килешү буенча үз йөкләмәләрен тулысынча үтәвенә кадәр гамәлдә була.

Әлеге Килешү предметы буенча яңа килешү төзелгән очракта, якларның әлеге Килешү буенча йөкләмәләре туктатыла.

7.3. Әлеге Килешүне үзгәртү Яклар инициативасы белән субсидия бирү кагыйдәләрендә билгеләнгән очракларда гамәлгә ашырыла һәм әлеге Килешүгә аның аерылгысыз өлеше булып торган өстәмә килешү рәвешендә рәсмиләштерелә.

7.4. Әлеге Килешүгә субсидияләрдән файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткеченең билгеләнгән мәгънәсен начарайтуны күздә тоткан үзгәрешләр кертү, шулай ук әлеге Килешүдә каралган йөкләмәләрне үтәү срокларын озайту, субсидияләрне бирү шартларын үтәү җиңеп булмый торган көч шартлары аркасында, шулай ук субсидия күләме кыскартылган очракта, әлеге Килешүнең гамәлдә булу срогы дәвамында рөхсәт ителми.

7.5. Якларның үзара ризалыгы булганда, әлеге Килешүне өзү мөмкин.

7.6. Әлеге Килешү ике нөсхәдә кәгазь документ рәвешендә, Якларның һәркайсы өчен берәр нөсхәдә төзелде.

**7. Якларның адреслары һәм банк реквизитлары**

«Башкарма комитет» «Субсидия алучы»

**8. Имзалар**

«Башкарма комитет» «Субсидия алучы»

Мөһер урыны

Мөһер урыны

________ 20__ ел, №__
килешүгә кушымта

# Субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында аларга ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр

1.Субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында аларга ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр

| Чыгымнар юнәлеше | | Субсидия бирү нәтиҗәсе | Үлчәү берәмлеге | | Юл коды | План күрсәткечләре | | Асылда ирешелгән күрсәткечләр | | | | Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр күләме, сум. | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| исеме | БК коды | | исеме | ОКЕИ буенча код | | килешү төзү датасыннан | шулардан агымдагы финанс елы башыннан | хисап датасына | | план күрсәткечләреннән тайпылу | | йөкләмәләр | акча йөкләмәләре |
| | | | | | | | | килешү төзү датасыннан | шулардан агымдагы финанс елы башыннан | абсолют зурлыкларда | процентларда | барлыгы | барлыгы |
| | | | | | | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 0100 | | | | | | | | |
| | | шул исәптән: | | | 0101 | X | X | | | X | X | | |
| | | | | | | X | X | | | X | X | | |
| | | | | | 0200 | | | | | | | | |
| | | шул исәптән: | | | 0201 | X | X | | | X | X | | |
| | | | | | | X | X | | | X | X | | |
| | | | | | | X | X | | | X | X | | |

2. Субсидия бирү нәтиҗәләре,
аларга ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр күрсәткеченә ирешү турында аналитик мәгълүмат

| Чыгымнар юнәлеше | | Субсидия бирү нәтиҗәсе | Үлчәү берәмлеге | | Юл коды | План күрсәткечләре | | Асылдаирешелгән күрсәткечләр | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | хисап датасына | | план күрсәткечләреннән тайпылу | | тайпылу сәбәбе | |
| исеме | К буенча код | | исеме | ОКЕИ буенча код | | килешү төзү датасыннан | шулардан агымдагы финанс башыел | килешү төзү датасын | шулардан агымдагы | абсолют зурлыкларда (гр. 7 - | гр процентларда. 9/гр. 7 х | код | исеме |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | нан | финанс елы башыннан | гр. 9) | 100% | | |
| | | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
| | | | | | 0100 | | | | | | | | |
| | | шул исәптән: | | | 0101 | X | X | | | X | X | X | X |
| | | | | | | X | X | | | X | X | X | X |
| | | | | | 0200 | | | | | | | | |
| | | шул исәптән: | | | 0201 | X | X | | | X | X | X | X |
| | | | | | | X | X | | | X | X | X | X |

Субсидия алучы _______ ___________________________________
(вазыйфасы) (имза) (имзаны аңлату)

Башкаручы ___________ _____________________
(вазыйфасы) (инициаллар, фамилия)

«___» ___________ 20__ ел